СОВЕТ ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

06.05.2025 г. Заинск № 193

**Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының 2018 елның 13 апрелендәге 104 номерлы "Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмә хакында" карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясенең 1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ номерлы Бюджет кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасының 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Кодексы нигезендә, Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Уставы белән, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының 2018 елның 13 апрелендәге 104 номерлы "Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы Нигезләмә хакында" карарына (Зәй муниципаль районы Шәһәр Советының 27.08.2020 №192, 27.12.2021 №79, 29.09.2022 №234, 18.11.2022 № 102, 13.06.2024 № 160, 09.12.2024 елның 180 номерлы карарлары белән кертелгән төзәтмәләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Күрсәтелгән карар белән расланган Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәдә:

2.2 пунктта "13 990 сум" сүзләрен "15 389 сум" сүзләренә алмаштырырга.;

2.6 пунктта "41 процент" сүзләрен "58 процент" сүзләренә алмаштырырга.

1.2. Күрсәтелгән карар белән расланган "Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы жирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турында" Нигезләмәгә 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә штат расписаниеләренә һәм локаль актларга тиешле үзгәрешләрне кертергә.

4. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» нда бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Билгеләргә:

әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә;

әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Башлыгы урынбасары С. В. Максимовка йөкләргә.

**Совет рәисе** **Р.Г. Кәримов**

Карарга кушымта

Акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфа исемнәре | Акчалата бүләкләү күләмнәре (сумнарда) |
| --- | --- |
| | 5 төркем |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 35 289 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 31 759 |
| Депутатлар | 16 910 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары | 14 373 |